СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 274 от 19.12.2018
на № ______ от ______

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының 2015 елның 20 маендагы 26-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр хакында” гы Законының 7 матдәсенә нигезләнеп һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең кайбер әгъзаларының вазыйфаларыннан китүләре сәбәпле, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2012 елның 26 апрелендәге 116нчы номерлы карары белән (2013 елның 23 сентябрендәге 211 номерлы, 2015 елның 30 апрелендәге 304 номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 20 номерлы, 2016 елның 28 апрелендәге 58 номерлы, 2016 елның 16 декаберендәге 86 номерлы, 2017 елның 29 августындагы 164 номерлы, 2017 елның 07 ноябрендәге 179 номерлы, 2018 елның 09 гыйнварындагы 193 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 203 номерлы, 2018 елның 04 маендагы 237 номерлы, 2018 елның 31 августындагы 254 номерлы, 2018 елның 09 ноябрендәге 269 номерлы редакцияләрендә) расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында”гы комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Комиссия составыннан Хәлилова Г.Х. чыгарырга;

1.2. Комиссия составына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетынының опека һәм попечительлек бүлегенең баш белгече Багманова Энҗе Фиргать кызын кертергә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының 2014 елның 09 апрелендә 245 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның

хокукларын яклау  комиссиясе Нигезләмәсен раслау турында”гы карарының 1нче пунктын; Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының 2018 елның 09 нояберендә 269 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау  комиссиясе Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында”гы карарының 1нче пунктын гамәлдән чыккан дип танырга

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы Башлыгы Р.Н. Минниханов